


2017 елнын 1 апреленнән яз башы хәрби хезмәткә чакырылыш кампаниясе башланып китте, ә контракт нигезендә хезмәт итvчеләрне ел әйләнәсендә чакыралар.
- Елына ике тапкыр журналистлар белән хәрби хезмәткә чакырылыш компаниясе турында пресс-конференция vткәрәбез, - дип сvзен башлады Мордовия Республикасы хәрби комиссары Игорь Валерьевич Тихомиров.- Мордовиядән 1000 артык кеше хәрби частьләргә хезмәткә жибәрелер. 2016 елны да шулкадәр ук сан иде һәм без планны тулы кvләмдә vтәдек. Алар арасында 300 (34,2%) югары белем алганнары.     Гомуммән, Мордовиядә хәрби хезмәткә яраклылар 84,4% тәшкил итә. Бу сан - Үзәк хәрби округ буенча ин югары кvрсәткеч. Үткән елны хәрби хезмәткә чакыруны Темников, Ельники, Теньгушево, Рузаевка, Краснослободск, Старошайгово, Атюрьево район комиссариатлары югары оештырылганлык белән vткәрделәр. Чакыру компаниясендә 25 жәмгыять оешмасы да катнашты: шәһәр казаклар жәмгыятьчелеге һәм Мордовия буенча Ботенроссия яшvсмер «Юнармия» оешмалары – бик тә активлар рәтендәләр , - ди очрашуда республиканын хәрби комиссары. - Хәрби хезмәткә ин беренче чиратта югары һәм урта һонәри белеме булган егетләр чакырыла. Ойләнгән һәм баласы булган ир-егетләр гадәттә Үзәк хәрби округы частьләрендә хезмәт итәләр һәм быел да шулай булачак.
2017нче елнын 1нче январеннан техникумнарын тәмамлап дипломнарын алгач кына хезмәткә чакыра башладык. Бакалаврны унышлы тәмамлап магистратурага кабул ителгәннәргә дә отсрочка бирелә. 2017 елнын яз башы чакырылышында альтернатив хезмәтне 3 яшvсмер Самарада, Тvбән Янашәһәрдә, Энгельста vтәр, дип чакырылыш компаниясе яналыклары турында да сойләп китте Игорь Валерьевич. - Хәрби хезмәткә озату районнарда 20 апрелдә башланса, ә Саранскта - 25. Жыелу пунктында, войск торенә карап тосле киемнәр, индивидуаль ашамлык һәм шәхси гигиена әйберләре бирелер, ди Игорь Валерьевич.
Мордовиядә контракт буенча хезмәткә сайлау пункты житәкчесе Виктор Владимирович Валенцов: “Үткән ел Мордовиядән контракт нигезендә хезмәт итvче 292 кеше иде. Контракт хезмәтендәгеләргә тиешле социаль пакет исә офицерларныкы кебек vк. Алар фатир, тиешле зарплата, льготалар белән тәэмин ителә. Шулары да кызыктыра яшvсмерләрне. Быел 82 контрактник озатылды инде ”.
Призывникларнын сәламәтлеге турында Виктор Александрович Якушкин, хәрбиләрнен саулыгын тикшерv комиссиясе рәисе, сойләде. Армиягә чакырылучыларнын 71-74% хезмәткә яраклылар дип санала - бу югары саннар. Алдагы елларда аш казаны, сояк-мускул авырулары остенлек алса, бvген - йорәк һәм кан, эндокрин системасы (13,7%)  хужалык итә. Минздрав бу авырулар буенча профилактик эшләргә игътибар

итсә, нәтижәләр булыр, дип котә чыгыш ясаучы, чонки аш казаны авыруларын киметтеләр инде.
Хәрби хезмәттән качып йорvчеләр турында да сvз булды. Барысыннан бигрәк кvрше регионнарга эшкә китеп, бу турыда хәрби комиссариат бvлегенә хәбәр итмичә кыенлык тудыралар. Быел «уклонистлар» саны - 800. Боларны юридик яктан «уклонистлар» дип әйтеп тә булмый,- ди Мордовия комиссары. - Чакыру комиссиясен vтеп чакыру алган, әмма чакыру пунктына килмәvчене шулай атыйлар. Андый 20 кеше судка бирелгән. Хәрби хезмәт vтv -  һәр егетнен изге бурычы ул. Чын егет авырлык-лар алдында куркып калмаска тиеш. Армиядән чыныгып, чын ир-егет булып, тормышны анларга, кыенлыкларны жинәргә ойрәнеп кайтканнарга кондәлек тормышта очраган проблемаларны чишv барыбер жинелрәк. Еллар узгач та әтиләрегез, бабайларыгыз кебек мин солдатта булдым дип горурланып әйтерлек булсын иде, дигән теләкне ишеттерде Мордовия хәрби комиссары.

**Наилә Насырова**